КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 9 февраль г.Казань № 73

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Белем алучыларны Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән туклану белән тәэмин итү очраклары һәм тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 ел, 26 сентябрь, 682 нче карары белән Белем алучыларны Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән туклану белән тәэмин итү очраклары һәм тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Белем алучыларны Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән туклану белән тәэмин итү очраклары һәм тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 ел, 26 сентябрь, 682 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 10 ноябрь, 861 нче һәм 2021 ел, 14 апрель, 247 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Белем алучыларны Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән туклану белән тәэмин итү очраклары һәм тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 пунктта:

«Социаль тәэмин итү бердәм дәүләт мәгълүмат системасыннан (алга таба – СТИБДМС)» сүзләрен «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасыннан» сүзләренә алмаштырырга;

«СТИБДМС» аббревиатурасын «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин